**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**29.04.2022 ел** **№ 461**

**2022 елның II кварталына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы кысаларында торак урыннарның бер квадрат метрының бәясен раслау турында**

«Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын, «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә торак урыннарның квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча уздырылган тикшеренү нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның II кварталына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы кысаларында торак урыннарның бер квадрат метрының бәясен 76 000 (җитмеш алты мең) сум күләмендә расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Хисамәтдинов